Балачак дөньясы

Balaçaq dənyası

Габдулла Тукай

Ğabdulla Tuqay

Мәсәлләр

Məsəllər



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ «MƏĞƏRİF» NƏŞRİƏTE

УДК 820/89(470)-93
ББК 84(2Рос=Тат)-7
Т72

Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комитеты ярдәмендә нәшер ителде.

Kitap Tatarstan Respublikası Ministrlar Kabinetı qarşındağı «Tatarstan Respublikası xalıqları tellәre turında» Tatarstan Respublikası Zakonın ğәmәlgә aşıru komitetı yәrdәmendә nәşer itelde.

Төзүче-редакторы НУРЗИДӘ НОТФУЛЛИНА
Tәzüçe-redaktorı NURZİDӘ NOTFULLİNA

Сериянең рәссамы ЛИЛИЯ ЗОЛОНДИНОВА
Seriәneŋ rәssamı LİLİӘ ZOLONDİNOVA

Рәссамы ИРИНА КОЛМОГОРЦЕВА
Rәssamı İRİNA KOLMOGORSEVA

Габдулла Тукай

Т72 Мәсәлләр/Mәsәllәr.— Казан: Мәгариф, 2002.— 47 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1280-х

ISBN 5-7761-1280-х

© «Мәгариф» нәшрияты, 2002

ҖИЛ ИЛӘ КОЯШ
Cil ilə Qoyaş

Берзаман Җил илә Кояш икәве: «Кайсыбыз Адәмнең киемен салдыра алыр?» — дип даулаштылар.

Җил, бар куәте илә исеп, Адәмнең киемен салдырырга тырыша иде. Җил катырак искән саен, Адәмнең киеме тәненә ныграк кына ябыша бара иде. Җил булдыра алмады.

Menə berzaman Qoyaş kütərelde. Bayağı Adəm, Qoyaşnıņ qızdıruına çıdıy almıyça, barça kiemnəren qultıq astına qıstırıp, yalaņğaç kitte.

Илә — белән.

ҖЫЛАН ИЛӘ БӘРӘН

Cılan ilə Bərən

Кое янында бер Җылан бөтен дөньяга каршы каһәрләнеп, ачуланып ята иде.

Җыланның ачулану өчен генә яратылган һәм зәһәрләнү хисеннән башка хисе юк икәне билгеледер.

Шуннан ерак түгел бер җирдә кечкенә генә яшь бер Бәрән, Җыланның барлыгыннан да хәбәре булмыйча, йөгереп, сикереп, рәхәтләнеп уйнап йөри иде.

Җылан — елан.

Menə berwaqıt Cılan Bərəngə taba əylənep, awızınnan uğın çığarıp, küzləre aldında hawa tomanlanıp, bɵten qanı qaynap, qəhərlənə başladı.

Cılannıŋ qılanışlarınnan ğəcəpləngən Bərən, anıŋ yanına uq kilep:

— İ Cılan! Soŋ bu qədər açulanırlıq min siŋa ni zarar kiterdem? — dide.

Cılan:

— Kem belsen? Bəlki, sin mine taptar ɵçen şulay sikergələp yɵri torğansıŋ,— dide.

* * *

Кемнең ки күңеле дустлык, сөешү кеби хисләрдән буш яратылган булса, аның каршында бөтен халык дошмандыр.

Кеби — кебек.

МАКТАНЧЫК КУЯН
Maqtançıq Quyan

Ерткучы хайваннар, бергәләшеп, бер зур Аюны аулап ектылар.

Табышны уртага салып үзара бүлешергә тотынганда, бер яктан Куян да килеп, Аюның колагына ябышты.

Башка ерткучы хайваннар Куянның болай батырчылык иткәненә гаҗәпләнделәр.

Həm alar, açulanıp:

— Əy sin, qıyıq ayaq! Sin nigə totınasıŋ? Ayunı awlağan waqıtta sineŋ ezeŋ də kürenməde bit! — dip qıçqırdılar.

Ерткучы — ерткыч.

Quyan, ber də aptıramıyça:

— Ə Ayunı urmannan kem quıp çığardı dip beləsez? — dide.

Quyannıŋ bu maqtanuı yırtquçılarğa bik qızıq wə kəlke kürengənlektən, aŋar, dəğwası buyınça, Ayu qolağın tapşırdılar.

* * *

Мактанчыклардан гәрчә көлсәләр дә, күп вакытта аларга өлеш тә тиядер.

АЮ МӘҖЛЕСЕ
Ayu məclese

Аю мәҗлес ясады. Мәҗлескә үзенең якын күргән Аю җенесен генә хасламаенча, күзенә кем күренеп, күңеленә кем килгәннәрнең берсен дә калдырмыйча чакырды.

Белмим, үзенең туган көне булдымы, әллә исемләнгән көне микән? Ни булса да булсын, мәҗлес шәп иде. Ашарга күп булган шикелле, эчәргә дә аз түгел иде. Кунаклар тезелешеп утырдылар. Аларның төрле аш вә эчемлекләрдән кәефләре килгән иде.

Кунакларның болай кәефләре килгәнне күргәч, Аю, тагы да кызыграк булсын дип, биззат үзе төшеп биергә кереште.

Хасламаенча — аермыйча.

Биззат үзе — туп-туры, үзе генә.

Təlke, monıņ biegənen kürgəç, bolay dip cırlıy başladı:

— Arı da barıp biiseņ,
Bire də kilep biiseņ;
Bigrək osta biiseņ,
Küz tiər dip belmiseņ.

Monı cırlağaç, yənəşə utırğan Büre, çıdıy almıyça, Təlkeneņ qolağına:

— Əy iptəş, nigə bolay ber də kileşməgən biüne — bürənə kebi ayaqları ilə dəp-dəp sikergənne bik osta, bik ciņel dip maqtıysıņ? — dide.

Təlke cawabında:

— İ Büre! Sin tik utır, xəzer minem bu maqtawım Ayunıņ xuşına kilsə, ul bezne tağın çaqırıp sıylar,— dide.

ЕГЕТ ИЛӘ КАРЛЫГАЧ
Yeget ilə Qarlığaç

Атасының вафатыннан соң бик бай мирас алып калган бер яшь Егет, артык дәрәҗәдә мутлык вә исрафка керешеп, берничә көн эчендә мал-мөлкәтнең барысын урнаштырып, өстендә бер искерәк туннан башка нәрсәсе калмады. Ул тунны да сатар иде дә, ләкин, вакыт кыш көне булганлыктан, суыкка туңып үләрмен дип курка иде.

Мут — азгын.
Исраф — акча туздыру.

Менә беркөнне бу мут Егет бер Карлыгачны күрүе илә тунны да сатып эчте. (Безнең җиргә Карлыгачның яз көне килгәне мәгълүмдер.)

Мут Егетнең уенча, инде һавалар яхшыланды, көннәр җылынды, суыклар да төн ягы аулаклыкларына куылды; мут егетнең тун сатуы тиешле иде.

Әмма яшь Егет «Бер карлыгач яз ясамый» дигән мәкальне оныткан иде.

Menə berwaqıtnı qaydandır isə yənə suıqlar, burannar çıqtı. Morcalarda bağana-bağana tətennər kürenep, çana tabannarı astında şığır-şığır qar tawışı işetelə başladı.

Biçara yəş Yegetnen, ğəyət tə əşegənlektən wə salqın üzəgenə ütkənlektən, ixtıyarsız, küzlərennən yəşləre atılıp çıqtı.

Berkənne Yeget uramda yərgəndə, üzenen tun sattırğan Qarlığaçının qar əstendə qatıp qalğan üləksəsen kürgəç, yanına kilep:

— İ bədbəxet Qarlığaç! Beterden sin mine! Sina ışanıp, min qış kəne tunsız qaldım,— dide.

Төн ягы аулаклыклары — төньяк.

БӘХЕТ

Bəxet

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер, эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман, ничектер, Бәхет күзгә күренмичә генә боларга кунакка килде дә, бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Bu waqıtta өç ağay-eneneņ berse səwdəgərlekkə totınğan ide. Dərxəl Bəxetneņ yərdəme ilə ni satsa — annan fayda, ni alsa, annan tabış itep, berniçə kəndə malı wə xəzinəsenen xisabı bulmağan ber bik zur bay bulıp kitte.

Şul uq Bəxet kilgən zamanda ikençe qərdəşe məxkəmədə kətib (pisar') ide. Bu da Bəxet arqasında xakimlek dərəcəsenə kütərelde; medal'lər birelde.

Sez inde өçençesenə Bəxet yərdəm itteme, diərsez.

Nik itməsen, itte: өçençe qərdəş çeben tota ide. Xəzer, Bəxetneņ bulışlığı ilə, qulın seltəgən sayın çeben tota, hiçber seltəgəne buşqa kitmi.

Bəxet qunaqqa ğına kilde, digən idek bit. Dərest; Bəxet ozaqlamadı, kitte.

İke qərendəş zur bay wə dəwlətle buldılar. Өçençese, haman yawız Bəxetne yamanlap, awıldan awılğa, suqrana-suqrana, qapçıq totıp telənergə kitte.

* * *

Укучы! Ушбу хикәядә кем гаепле икәнен үзең хаким булып табып хөкем ит.

Дәрхаль — шунда ук.
Мәхкәмә — суд.
Кардәш, карендәш — туган.
Хакимлек — судьялык.

БАЛА КОЗГЫН
Bala Qozğın

Һавадан бер Каракош килеп, куй көтүе өстенә төште дә туганына бер-ике генә ай булган бер Бәрәнне тырнагына элеп китте.

Бу хәлне якыннан гына карап торган бер Козгын баласы күреп, үзенә үзе:

«Инде алгач, зуррак Куйны алырга кирәк иде; бу каракошларда бер дә акыл юк икән, андый маңка куйлар илә нигә тырнак пычратырга кирәк! Бу кадәрле зур көтүдә Бәрәннән башкалар да бар ич. Менә мин, теләсәм, нинди Куйны алырга белермен»,— дип сөйләнә-сөйләнә, көтү өстенә очып

барып, барча куйиларны күздән кичергәндә, моңар Сыердан аз гына кечкенә бер Кучкар күренде.

Бу Кучкар безнең бала Козгынның күңеленә ошагач, ул, озак уйламаенча, Кучкарның бөдрәләнеп-бөдрәләнеп оешкан киез шикелле толыбына үткен тырнакларын батырды.

İnde, beznen qanatlı awçıbıznın uyınça, tabış bik zur, tik eş kütərep oçuda ğına qalğan. Əmma hər cirdə tuğrı kilgən «yəş-lek — cülərlek» məqəle beznen bala Kozğınğa da qıyıq kilməde. Biçara Qozğınçıq azıqnı kütərergə keçənə, azaplana, wə xəlbüki tege Quçqarnın awçı tırnağına eləkkənennən xəbəre də yuq; ul əwwəlgeçə tınıç qına awızındağı çirəmne çəynəp tik tora.

Xəzer inde beznen awçı awdan əmid kiste. İnde, içmasam, üze genə qotılsa da küp şeker itməkçe bula. Ləkin açküzlelek ilə tırnaqlar bik tirən batqan, qadaqlap quyğan şikelle, selketer də xəl yuq.

Bu xəlne kətüçelər kürdelər də, Qozğınnın tırnaqların pıçaq belən kisep, keçkə genə aldılar. Sonra, oçıp kitməsen dip, awçının qanatların da kisep, üzen balalarğa uynarğa birdelər.

* * *

Бер төрле гакыллырак татар сәүдәгәрләренең Мәскәүдән бер-ике мең генә алып, эшне машина кеби әйләндергәнен икенчеләре күрәләр дә, алардан көлеп, биззат үзләре Мәскәүгә барып, кырык-илле меңлек векселькә кул куялар да бөтенләй ушбу яшь Козгын хәленә төшәләр.

Биззат үзләре — туп-туры.

УМАРТА КОРТЫ ИЛӘ ЧЕБЕННӘР

Umarta qortı ilə çebennər

Ике чебен, чит мәмләкәтләргә китәргә хәзерләнеп, үзләре илә бергә китәргә Умарта кортын да чакыра башладылар.

Бу чебеннәр чит җирләрнең бик яхшы икәнен байгушлардан ишеткәннәр иде.

Чебеннәр ник китмәсеннәр? Туган җирләрендә боларны рәнҗетәләр һәм, чакырылмаган кунак шикелле, бичараларны ашъяулык тирәсеннән куалар, татлы ашларны да ашатмыйлар...

Мәмләкәтләр — илләр.
Байгуш — ябалак.

Həmmə aşamlıq nərsələr əstenə pıyala qalfaqlar qaplap, mısqıl itkən şikelle, tik çebennərneņ küzləren genə qızıqtıralar.

Poçmaq taraflarına bətenləy barır xəl də yuq: anda usal ürməküçlər aw qorğannar.

Onıtılmasın əle, Umarta qortı bolarğa ni cawap birde?

Ul:

— Miņa tuğan-üskən cirem qəderle. Min üzemneņ kərəzle balım ilə alpawıtlarnı, baylarnı, xətta awıl keşeləren də üzemə ğaşıyq ittem. Min monda da səyekle. Əmma sezgə süzem yuq, sez teləsəgez qaya barığız. Ləkin belegez ki, sezneņ hər cirdə də bəxetegez ber bulır. Əgər sez haman əzer aşnı aşaw ğədətegezne taşlamasağız, qaya barsağız da sezgə xərmət itməslər,— dide.

* * *

Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр.

ТАШБАКА ИЛӘ КУЯН
Taşbaqa ilə Quyan

Ташбака илә Куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.

Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.

Quyan berzaman yoqısınnan uyanıp qarasa, Taşbaqa əllə qayçan tawğa barıp citkən!

İnde beznen Quyan artqa qalğanına ükende də, xurlandı da, əmma ni fayda?

* * *

Үзеңдәге көчкә алай ышанырга ярамый. Кечкенә генә дошманга да зур дошманга хәзерләнгән кеби хәзерләнергә кирәк.

ТАВЫКЛАР ИЛӘ КАРАКОШ

Tawıqlar ilə Qaraqoş

Каракош бер кояшлы якты көндә, туйганчы сәер итеп, рәхәтләнеп калмак нияте илә, биек һаваларда, яшеннәр туа торган җирләрдә канатларын акрын һәм бик вәкарь берлән генә селкеп оча иде.

С ә е р — *бередә:* сәяхәт итеп.
В ә к а р ь — олысымаклык.

Берзаман, ни сәбәптәндер, әллә күп оча торгач, арып, хәл җыймак өченме, бу кошлар падишаһы бер кисмәк өстенә килеп кунды.

Падишаһның, шул җирдә генә бакчада булган имәннәргә, наратларга кунмыйча, кисмәк өстенә кунуына гаҗәпләнерлек тә бар. Әллә, кисмәккә аның мәрхәмәте килеп, кисмәк өстендә падишаһ утырганлык берлә мөшәррәф булсын, диеме? Ни булса да булыр, падишаһларның серен белер хәл юк, Каракош шул кисмәк өстендә бераз вакыт утырып торды.

Monıŋ monda utırğanın kürgən təkle ayaqlı, bürekle Tawıq iptəşe ilə bu tübəndəge süzlərne səyli ide:

— İ iptəş, bu qaraqoşlar ni əçen bik qəderle bulalar, hərwaqıt tellərdə səylənələr həm aqçalarğa da alarnıŋ surəten təşerələr? Əgər bu xərmət alarnıŋ oçuları əçen bulsa, menə min də, əgər teləsəm, kismək əstenə quna alam. Ul qaraqoşlarnıŋ da küzləre, ayaqları barıber bezneke şikelle iç. İptəş, əle üzeŋ də kürdeŋ: bu Qaraqoş nindi tübən oçtı!

Qaraqoş, bu süzlərne tıŋlap torırğa çıdıy almıyça:

— İ duslar! Qaywaqıtta bezgə Tawıqtan da tübən təşərgə turı kilədеr. Əmma tawıqlarğa hiçber waqıtta da bolıtqa citü nasıyb bulmıydır! — dide.

Мөшәррәф булу — югары дәрәҗәгә ирешү.



БҮРЕ ИЛӘ ТЫЧКАН

Büre ilə Tıçqan

Соры Бүре көтүдән бер Куйны алып китте. Әлбәттә, кунакка алып китү түгел инде. Бер урманның аулак почмагына гына кереп, мискин Куйны ертып, өзгәләп, үзенең табигый ачкүзлеге илә ашый башлады. Әмма никадәрле ашаса да, берьюлы ашап бетерә алмыйча, итне икенче ашарга калдырып, үзе, көчкә генә сулыш алып, кибән төбенә ятты.

Büredən yıraq tügel ber oyada yatqan Tıçqannıņ borınına it ise kergəç, Tıçqan, küp uylamıyça, qamıllar, çirəmnər, quyı

Мискин — мескен.

ülənnər arasınnan kilep, üze kebi keçkenə genə ber it kisəgen elde də aldına-artına qaramıy sızdı.

Büre, bu eşne kürgəç, ğaqıldan şaşıp, bөten urmannı yanğıratıp:

— Qarawıl! Xarap buldım! Totığız qaraqnı! Malımnı urladılar! — dip qıçqıra başladı.

* * *

Дустлар! Бүре бу малны үзе кайдан алган иде?

МӘЧЕ ИЛӘ САНДУГАЧ
Məçe ilə Sanduğaç

Мәче Сандугачны тотып, бичараның тәненә үткен тырнакларын батырды. Һәм шул арада тәмле генә, сөчүк кенә тел илә Сандугачка бу сүзләрне әйтә башлады:

— И Сандугачым, җаным! Мин сине дөньяда беренче сайраучы дип ишетә идем, синең сайравың һәртөрле музыкалардан матур булганлыктан, урмандагы көтүчеләр, ат ашатучылар — һәммәсе биһуш булганнар, имеш.

Шуның өчен мин сине тотып, үз алдымда сайратып карамакчы булган идем. Селкенмә, тиберченмә, кошчыгым, мин сине бөтенләй үк ашамыйм әле, курыкма, сайра әле, дустым. Әгәр сайрасаң, мин сине азат итәрмен, болынлыкларда,

---

Сөчүк (сөче үк) — төче үк.
Биһуш — һушсыз.

куаклыкларда иркенләп йөрерсең. Син мине музыкага әһел түгел, иш түгел дип уйлама. Мин үзем дә эч пошкан вакытларда бертуктамый мыраулап, мияулап йөримен.

Məçe bolay söyləgəndə, Sanduğaç, əcəle yaqınayğannı sizep, qızğanıçlı tawış ilə çırıldıy ide.

Məçe isə Sanduğaçnı mısqıl itep:

— İ miskin! Şuşı tawışıņ ilə dönyağa isemeņ taraldımı? Həm bu çırıldawıņ öçen yegetlər, qızlar telendə söyləndeņme? Süzem yalğan bulmasın, bu tawış qına minem balalarımda da bar. Sınadım, beldem, Sanduğaç, sineņ sayrawıņ tatlı tügel ikən, inde tatıp qarıym əle, iteņ təmleme ikən? — dip, bəxetsez şağirne walçığın da qaldırmıyça təmamladı.

* * *

Дустлар! Уйлап карыйк әле: Мәче тырнагында Сандугач сайрармы?

Музыкага әһел түгел — музыканы аңлаучы түгел.



ИКЕ САБАН

İke saban

Ике сабан, икесе бер үк тимердән, бер үк һөнәр йортында эшләнеп, базарга чыгарылганнар иде.

Боларның берсе Иген игүчегә сатылып, ул аны алгач ук эшкә кушты. Аның белән җир сөрә башлады. Шул рәвешчә, бу Сабан һәр җәйне эшләп, аңар тик ятарга туры килми иде.

Икенче Сабан исә бер Сәүдәгәр кулына эләгеп, аның кибетендә ауналып, эшсез ята иде.

Шулай озак заманнар үткәч, бу ике сабан бер җирдә очраштылар.

Kibetçedəge Saban, küp yıllar eşsez yatqanlıqtan, təmam tutığıp, sarğayıp, qaranğılanıp betkən ide.

İgen igüçedəgese isə küp eşləp açılğan həm kəzge şikelle yaltırap tora ide.

Tutıqqan Saban üzenen̡ iptəşenen̡ bolay maturlanğanın kürgəç, an̡a:

— İptəş, sin ni səbəptən bolay yaltırıysın̡ da, min ni səbəptən mondıy tutıqqan həm qaran̡ğılanğan? — dip səal' birde.

İptəşe an̡ar:

— Minem yaltırawım tırışuımnan kilde. Əgər ğəmer buyı kibet idənendə qırın yatıp torsam, min də sinen̡ təsle qaralır həm yəmsezlənər idem,— dip cawap birde.

Сөаль — сорау.

ЧҮЛМӘК ИЛӘ КАЗАН

Çülmək ilə Qazan

Чүлмәк илә Казан, бик дустланып, гомер буе аерылмаска вәгъдә куйдылар.

Чүлмәк балчыктан гына ясалып, Казан чуеннан булганлыктан, Казанның дәрәҗәсе югарырак булса да (җә, дустлашуда исәпләшү нигә кирәк?), болар дустландылар.

Шул дустлык буенча, учак алдында, мич башында бу ике дуст һаман бергә күренәләр, дөресте генә, бер-берсеннән бер адым да аерылышмыйлар иде.

Menə berzaman Qazan bu fani dənyanı tamaşa itep kürmək niətenə təşte. Yuğarıdağı wəğdəne bozarğa yaramağanlıqtan, Qazan Çülmək ilə bergə ber arbağa utırıp kittelər.

Səfər bit, axrısı. Şeş-şeş çığıp torğan taşlı tawlardan, əllə nindi tigezsez küperlərdən ütərgə turı kilə. Qazannıŋ xəle tınıç, əmma Çülməkneŋ xəle minuttan minutqa naçarlana bara ide.

Şulay bulsa da, Çülmək, üzeneŋ Qazan berlən dust bulğanına quanıp, asla kire qaytunı uylamıy, haman bara ğına ide.

Yıraqmı, niqədər cir yərgənnəren belmim, əmma, əygə qaytqanda, Çülməkneŋ tetelep betkən kisəklərе genə qaytqanın bik açıq beləmen.

* * *

Укучы! Дустлыкта берлек, тигезлек, тиңлек кирәклеген әйтмәсәм дә беләсең инде.

Асла — һич тә.

ИКЕ ЭТ
İke et

Баеның хезмәтеннән бер дә ялыкмаган, чын күңелле, хыянәтсез Муйнак, үзенең иске дусты Актырнакның һәйбәт мендәрдә, тәрәзә төбендә утырганын күргәч, янына килеп, гүя анасын күргән шикелле булып, каннары кайнап, күзләрен яшьләндереп, тәрәзә янында койрыгын болгап, сикереп, гүя Актырнакның рәхәтенә көнләшкән шикелле булып тора иде.

Шул арада дусты Актырнакның хәлен сораша башлап:

— Йә, дуст, ни хәл? Ни эшләп торасың? Кәефләр хушмы? Мин карап торамын: сине бөтенләй боярлар шикелле кадерли башлаганнар. Әле исеңдәме? Күптән түгел синең илә мин, ачлыктан аз гына үлмичә, абзар каравыллый торган идек,— диде.

Aqtırnaq, cawapqa kereşep:

— İ dust! Min xəzer bik bəxetle, minnən Xuca həm Xatını üzlərenen cannarın da qızğanmıylar. Şəker Xodayğa, baylıqta, rəxəttə toramın, altın-kəmeş tabaqlardan ğına aşıymın, aşap tuyğaç, kəyeflənəm, Xuca xatını ilə uynıy başlıymın. Əgər arısam, xətfə palaslarda, yomşaq kərsilərdə yatıp awnıymın,— dip, üz bəxeten səyləp təmam itkəç:

— Ə sin, Muynaq, ni xəldə torasıņ? — dide.

Muynaq ta, üz xəlen bəyanğa totınıp:

— Minem tormışım haman üzeŋ kürgəndəge şikelle: suıqqa da tüzəm, açlıqqa da çıdıym, Xucamnıŋ yortın saqlap, açıq hawada yanğırlarğa da çılanam. Əgər waqıtsızraq ərsəm, başıma tayaq ta qabul itəm. Min ğəcəplənəm, Aqtırnaq dust, sin üzeŋ kəçsez həm keçkenə bulıp ta, bu qədər bəxetkə, bu çaqlı rəxətkə niçek eləkteŋ? — dide.

Aqtırnaq yənə süzgə kereşep, kəlemserəp:

— İ dustım! Keşe bəxetenə kənləşü gənahtır. Beləmseŋ, min art ayaq ilə yəri alğanım əçen şulay bəxetle buldım,— dide.

* * *

Дөньяда күп кешеләр бар ки, алар арт аяк илә йөргәннәре өчен генә бәхетле булалар.



ИШӘК ИЛӘ САНДУГАЧ
İşək ilə Sanduğaç

Ишәк Сандугачны күрде дә, аның янына килеп:

— Тыңла әле, дустым! Миңа сине, ул сайрарга бик маһир, дип мактадылар. Менә мин үз колагым илә синең тавышыңны ишетмәкче вә яхшы-начарлыгына үзем хөкем итмәкче булдым,— диде.

Сандугач, дәрхаль үзенең һөнәрен күрсәтергә башлап, әллә тагы мең төрле көйләргә борып сайрарга кереште.

Маһир — оста.
Дәрхаль — шунда ук.

3 Б-750

Ул, бер чут-чут итеп куеп, бер сызгыра, бер назиканә генә, тавышын әкренләтеп, бер бөтен урманга вак кына ядрә сипкән кеби яңгыратып җибәреп, ничек тә булса матуррак сайрарга тырыша иде.

Sayrawnıŋ tə'sirennən iskən cillər həm sayrap torğan waqtəyək qoşlar tuqtadılar. Kətülər ber urınğa yattılar. Kətüçe də, sulışın kəçkə genə alıp, Sanduğaç tawışın erep, izelep tıŋlıy ide.

Sanduğaç sayrawdan tuqtadı.

Şul waqıt beznen İşək, maŋlayın cirgə quyıp:

— Əye, Sanduğaç, sin həybət sayrıysıŋ, sine ber də küŋelsezlənmi genə tıŋlap bula. Ləkin şunısı qızğanıç: sin beznen kürşedəge Ətəç belən tanış tügel ikənseŋ. Əgər sin anıŋ belən tanışıp, annan beraz əyrənsəŋ, tağı da matur sayrar ideŋ,— dide.

* * *

Ярабби, син безне дә мондый хакимнәрдән сакла!

Назиканә — нәфис.

Хаким — хөкем чыгаручы, катгый фикер әйтүче.

БЫТБЫЛДЫК
Bıtbıldıq

Бытбылдык, диңгезгә кереп, барча җан-җанвар, кош-кортка:

— Мин хәзер бу диңгезне яндырам! — дип мактанды.

Бу — простой хәбәр түгел: шул ук сәгатьтә бөтен җир йөзенә, су төпләренә, урман араларына таралды. Барча су падишаһлыгының халкына зур хәвеф төште; һәркайсының җаннары башларына сачрады. Һавага карасаң, көтү-көтү кошлар килә; урманнан гөруһ-гөруһ хайваннар шәһәрдә

Ж а н н а р ы б а ш л а р ы н а с а ч р а д ы — бик нык курыктылар.
Г ө р у һ - г ө р у һ — көтү-көтү.

пожар булганда халык җыелган шикелле җыелалар. Һәрберсе: «Диңгез ни төсле булып янар икән?» — дип уйлыйлар иде. Бу хәбәр авылдагы, шәһәрдәге кешеләргә дә таралган булырга кирәк. Кешеләр дә, бер кулларына кашык, икенчесенә икмәк тотып, балык шурпасы ашарга дип, берсен берсе егып, таптап, ашыгып чабалар.

Tamaşaçılar kilep bette; hərkem telsez keşe şikelle tawışsız-tınsız diŋgezgə küzen tekəp tora ide.

Tik qaysı arada pış-pış qına:

— Menə diŋgez qaynıy başlar, menə yanar,— digən tawışlar işetelə ide.

Keşelər, xaywannar, qoşlar kətələr, kətü, uttan da esserək bulıp, eçləren yandıra.

Aptırağaç, ber-bersenə:

— İçmasam, qaynıy başlamadımı? — dilər ide.

Diŋgez isə yanmıy da, qaynamıy da.

Axırda ni buldı?

Bıtbıldıq oyatınnan küzen yomıp oçıp kitte.

Dənyağa danı çıqtı, əmma diŋgez yanmadı.

* * *

Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин: бер эшнең очына чыкмыйча мактану кирәкмәс.



ЯШЬ АГАЧ
Yəş Ağaç

Мужикның урманда балта тотып барганын бер яшь Агач күрде дә, Мужикка кычкырып:

— И Агай! Зинһар, хәлемә мәрхәмәт итеп, минем тирәягымдагы карт агачларны кисә күр; мин, алар каплап торганга күрә, якты дөньяны күрә алмыйм вә иркенләп, рәхәтләнеп үсә алмыйм; тамырларым да, шушы карт агачлар тыгызлаганга күрә, кирәгенчә җәелә алмыйлар. Миңа җил дә, кояш нуры да керә алмый. Әгәр син карт агачлардан мине коткарсаң, мин бер ел эчендә урманның беренче матур Агачы була алыр идем, бөтен сахра минем күләгә илә

капланыр иде. Менә, күрәмсең, шул картлар зарарыннан минем калынлыгым һаман чыбык шикелле генә,— дип ялынды.

Мужик, шулай дигәч, үзенең беренче дустына хезмәт күрсәткән шикелле, безнең яшь Агачка ярдәм күрсәтмәкче булып, кулына балтасын иплән тотып, аз гына вакыт эчендә теге карт агачларның һәммәсен кисеп аударды.

Менә инде яшь Агачның күңеле булды, аңар дөнья иркен калды.

Ләкин бу куанулар урынлымы?

Xəzer inde biçara yəş Ağaçnı qoyaş yandıra, cə bozlı yanğır kəyefen ala, cə qom, tufraq buranı kilep, cirgə çaqlı bөgep, ielderep kitə.

Kөnnərdə ber kөn bik qatı cille dawıl kilde də yəş Ağaçnı şartlatıp sındırdı da kitte.

Bu xəlne kürep torğan ber Cılan, cirdə sınıp yatqan yəş Ağaçqa qarap:

— İ yəş bala! İnde kemgə üpkələməkçe bulasıņ? Bu bələ sineņ üzeņnən buldı. Əgər sin qart ağaçlarğa tarlanmağan bulsaņ, ul ağaçlar sine cildən, yanğırdan saqlağan bulırlar ide; sin ışıqta, tınıç qına, rəxətlənep üsər ideņ.

Ğaqılsız! Ul ağaçlarğa da mөņge suı sipməgənnər ide. Əgər alarnıņ ğөmere betkənen kөtsəņ, aņarçı sin də üsep, qüətləner ideņ, üz nəwbəteņdə sin də zur Ağaç bulıp, dөnyanı kürep torır ideņ, həm bu bələlər başıņa kilməgən bulır ide,— dide.

Нәүбәтеңдә — чиратында.

КЕШЕ ИЛӘ АРЫСЛАН

Keşe ilə Arıslan

Көчле булмактан гакыллы булмак кат-кат артыктыр.

Моңар ышанмаган кеше, менә бу хикәячекне укыгач, гакылның артыклыгына канәгать хасил итәр.

Бер Аучы, үзенең авын агачлар арасына җәеп, нинди булса да табыш көтеп торганда, яңлыш үзе Арыслан тырнагына эләкте.

Арыслан, каһәрләнеп:

— Бет, и бәдбәхет мәхлук! Менә минем тырнагымда

Канәгать хасил итү — ышану.

тикшереп карыйк әле, синең тазалыгың вә көчлелегең кайда икән? Сез, адәм балалары, үзеңезне бөтен дүрт аяклы хайваннарга (хәтта арысланнарга да!) падишаһ дип йөрисез, имеш. Менә хәзер бу дәгъвагызның тиешле-тиешсезлеген карарга форсат табылды,— диде.

Бичара Аучы Арыслан тырнагыннан зәгыйфь кенә тавыш илә:

— Без сездән көч вә куәт ягыннан өстенлекне дәгъва кыйлмыйбыз, бәлки гакыл илә сездән югарылыкны дәгъва итәбез. Менә мактанырга батырчылык итәмен ки, мин хәзер бу җирдә үземнең гакылым илә шундый эш эшләрмен ки, сез ул эшне көчегез берлән эшли алмассыз,— диде.

Arıslan:

— Søyləmə! Min seznen maqtanğan əkiətlərenezne tıŋlap arıdım inde...— dide.

Awçı:

— Yuq, padişahım, əkiət tügel, min xəzer ostalığımnı küz aldıŋda kürsətəm. Əgər süzem yalğan bulsa, minem qaçıp qotılır xəlem yuq, soŋınnan da aşarğa ølgerersen. Menə minem ağaç arasında cəygən ürməküç oyalarım bar; şunıŋ astınnan min ğaqılım berlən çığa alam, həm sin də køçen berlən çığıp qara. Ənə üzeŋ də kürəseŋ: ul — ürməküç oyası, taş stena tügel, ənə az ğına cilgə də selkenep toradır.

Arıslan:

— Cə, elek üzeŋ çığıp qara! — digəç, Awçı, məharət belən, şoma ğına aw astınnan çıqtı.

Məharət — осталык.

Anıņ artınnan Arıslan da, cəyədən atılğan uq şikelle sikerep, aw astına barıp kerde.

Əmma bəxetsez Arıslannıņ aw astına ğəmerdə də kergəne yuq ide. Miskin xaywan awğa çornalıp qaldı.

Ğaqıl kəçne ciņde.

Kəçle Arıslan hələq buldı.

МӘЧЕ БАЛАСЫ ИЛӘ СЫЕРЧЫК

Məçe balası ilə Sıyırçıq

Кайсыдыр бер өйдә бер Сыерчык бар иде.

Үзе сайрау һөнәрендә начар булса да, бик гакыллы вә фикерле булганлыгыннан, сайравының начарлыгыны яшерә аладыр иде.

Шул ук өйдә бер Мәче баласы да булып, Сыерчык монының илә араларына кыл да сыймаслык дәрәҗәдә дуст иде.

Мәче баласы да бик җуаш булганлыктан, Сыерчыкка сөйкемле иде.

Бервакыт боларның хуҗалары кунаккамы, кайдадыр китеп бик озак торгач, Мәче баласы һәркөн барып ризык-

---

Җуаш — юаш.

лана торган ашъяулыктан аерылып, моны ачлык, кыйхытлык җөдәтә башлады.

Мәче баласы, рузаның катылыгы үзәгенә үткәнлектән, идән буенда кызганыч тавышлар илә мыраулап, күңелсезләнеп йөри иде.

Бу хәлне күреп торган Сыерчык Мәче баласына киңәш юлында шушы рәвешчә сүзгә кереште:

— İ dustım Pesi! Sin bigrək saf küŋelle wə cuaş tabiğətle ikənseŋ, minem sineŋ üz faydaŋnı üzeŋ belməweŋə isem kitə. Ənə borın astınduq çitlektə Turğay asılınıp tora. Çitlek işegen aç ta şul Turğaynı alıp aşa. Sin ğafil bulma, siŋa balalığıŋnı taşlarğa waqıt inde. Bu dənyada kem kəçle bulsa, ul ni qıylsa da irekle.

Fəyləsüf Sıyırçıqnıŋ bu süzlərе Məçe balasınıŋ xuşına kitep, ul, dərxəl çitlekne açıp, Turğaynı çığarıp, totıp aşadı.

Bu Turğay gərçə Məçene tuydırırlıq bulmasa da, yərək yalğarğa yaradı.

Soŋra Məçe balası, bətenləy tuyunıŋ da yulın ezləp, yaqyaqqa qarandı da, ozaq uylamıyça, tege kiŋəşne əyrətkən xəlfə Sıyırçıqnıŋ üzen də təğzim berlə genə aşadı.

* * *

Берәү кардәшенә кое казыса, үзе төшәр.

Кыйхытлык — каты ачлык, кытлык.

Руза — ураза, дини йола: иртән таң вакытыннан башлап, кич шәфәкъ батканчы ашамыйча тору.

Гафил булма — сизмичә калма.

Фәйләсүф — философ.

Хушына китү — ошау.

Тәгъзим берлә генә — олылап кына.

Язылышы		Әйтелеше	
Басма хәреф	Язма хәреф	Латиница	Кириллица
A, a	*A, a*	a	а
Ə, ə	*Ə, ə*	ə	ә
B, b	*B, b*	be	бэ
C, c	*C, c*	ce	җэ
Ç, ç	*Ç, ç*	çe	чэ
D, d	*D, d*	de	дэ
E, e	*E, e*	e	е(э)
F, f	*F, f*	ef	эф
G, g	*G, g*	ge	гэ
Ğ, ğ	*Ğ, ğ*	ğı	гъ
H, h	*H, h*	he	һэ
I, ı	*I, ı*	ı	ы
İ, i	*I, i*	i	и
J, j	*J, j*	je	жэ
K, k	*K, k*	ke	кэ
Q, q	*Q, q*	qı	къ
L, l	*L, l*	el	эл
M, m	*M, m*	em	эм
N, n	*N, n*	en	эн
Ņ, ņ	*Ņ, ņ*	eņ	эң
O, o	*O, o*	o	о
Ɵ, ɵ	*Ɵ, ɵ*	ɵ	ө
P, p	*P, p*	pe	пэ
R, r	*R, r*	er	эр
S, s	*S, s*	es	эс
Ş, ş	*Ş, ş*	şa	ша
T, t	*T, t*	te	тэ
U, u	*U, u*	u	у
Ü, ü	*Ü, ü*	ü	ү
V, v	*V, v*	ve	вэ
W, w	*W, w*	we	вэ(у)
X, x	*X, x*	xa	ха
Y, y	*Y, y*	qısqa i	кыска и
Z, z	*Z, z*	ze	зэ

ЭЧТӘЛЕК

Җил илә Кояш 3
Җылан илә Бәрән 4
Мактанчык Куян 6
Аю мәҗлесе 7
Егет илә Карлыгач 10
Бәхет 12
Бала Козгын 14
Умарта корты илә чебеннәр 17
Ташбака илә Куян 19
Тавыклар илә Каракош 20
Бүре илә Тычкан 23
Мәче илә Сандугач 24
Ике сабан 26
Чүлмәк илә Казан 28
Ике эт 29
Ишәк илә Сандугач 32
Бытбылдык 35
Яшь Агач 38
Кеше илә Арыслан 40
Мәче баласы илә Сыерчык 43

ЛИТЕРАТУРНО-ХУДОЖЕСТВЕННОЕ ИЗДАНИЕ

Для детей и юношества

Тукай Габдулла

БАСНИ

(на татарском языке)

Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*
Рәсемнәрне компьютерда *Л. Р. Вафина*
һәм *Э. Ф. Нурмөхәммәтова* эшкәртте

Нәшриятка 183 нче лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.09.2002. Форматы $84\times100^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы
4,68 + форз. 0,39. Нәшер-хисап табагы 2,38 + форз. 0,7.
Тиражы 8000 д. Заказ Б-750.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.